РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«9» апрель 2025г. г. Альметьевск №355

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында чаралар үткәрүгә вәкиллек чыгымнары турында Нигезләмә хакында» 2015 елның 16 июнендәге 476 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына таянып, базар бәяләре артуга һәм кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында чаралар үткәрүгә вәкиллек чыгымнары турында Нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 16 июнендәге 476 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 10 августындагы 86 номерлы, 2017 елның 25 сентябрендәге 201 номерлы, 2019 елның 28 августындагы 315 номерлы, 2019 елның 16 декабрендәге 348 номерлы, 2022 елның 05 октябрендәге 171 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга кушымтада «Акчалар алу һәм алардан файдалану тәртибе, исәптә рәсмиләштерү һәм чагылдыру» IV бүлегенең 16 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«РФ Финанс министрлыгының «дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары, дәүләт фәннәр академияләре, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре өчен бухгалтерлык исәбе счетларының бердәм планын һәм аны куллану буенча Инструкцияләрне раслау турында» 2010 елның 01 декабрендәге 157н номерлы боерыгы, Россия Финанс министрлыгының «Дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификациясен куллану тәртибен раслау турында» 2017 елның 29 ноябрендәге 209н номерлы боерыгы буенча исәпкә алуда делегацияләрне кабул итү һәм аларга хезмәт күрсәтү чыгымнары (вәкиллек чыгымнары) дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификациясе чыгымнарының 226 нчы «Башка эшләр, хезмәтләр» статьясына кертелергә һәм әлеге чыгымнарга акчаларны исәптән чыгару бухгалтерлык исәбендә 1 401 20 «агымдагы финанс елы чыгымнары» счеты буенча чагыла;

1.2. «Әлмәт шәһәре һәм Әлмәт районында киңәшмәләргә (Әлмәт муниципаль районы Советы сессияләренә), башка массакүләм чараларга килүче чаралар үткәрүгә, делегацияләргә һәм аерым затларга (шул исәптән чит ил кешеләренә)

хезмәт күрсәтүгә чыгымнар нормаларын» нигезләмәсенә 1.1 нче кушымтасында 3, 4 пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

| № | Чыгымнар төрләре | Сумма, сумнарда |
|---|---|---|
| 3 | Ашау өчен түләү (иртәнге аш, төшке аш, кичке аш) 1 кешегә: | |
| | Иртәнге аш | 1500,00 гә кадәр |
| | Төшке аш | 3000,00 гә кадәр |
| | Кичке аш | 3500,00 гә кадәр |
| 4 | Читтән килгән делегацияләр катнашында сөйләшүләр, конференцияләр һәм башка массакүләм чаралар үткәргәндә буфет хезмәте күрсәтү (фуршет) 1 кешегә | 1200,00 гә кадәр |

1.3. «Әлмәт шәһәрендә һәм Әлмәт районында делегацияләр катнашындагы чараларда басма продукция, чәчәк бәйләмнәре тапшыру чыгымнары нормалары» нигезләмәсенең 1.2 кушымтасында 3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| № | Чыгымнар төрләре | 1 бер.продукция, сумнарда |
|---|---|---|
| 3 | Юбилей даталары уңаеннан, район башлыгы исеменнән бүләкләр тапшыру өчен, бәйрәм чараларында, район башлыгы кабул итүләрендә, шәһәрнең һәм районның Мактаулы гражданнарын хөрмәтләүдә, рәсми чараларда чәчәк бәйләмнәре сатып алу | 3000,00 гә кадәр |

1.4. Нигезләмәгә 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итү:

«Вәкиллек чыгымнарын исәптән чыгару комиссиясе составы»

Каюмов Айдар Марат улы - комиссия рәисе, Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;

Кәшфетдинова Ләйсән Тәлгат кызы - Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы;

Саматова Светлана Владимировна - Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы;

Фәсхетдинов Илнур Равил улы – Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының эшләр идарәчесе;

Шәмсуллин Тимур Расих улы - Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының гомуми бүлеге җитәкчесе урынбасары.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»на (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, налоглар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Грушин А.И.).

Муниципаль район башлыгы
вазыйфаларын башкаручы

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»

Р.Е. Әфләтунова